РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№_130**

«2015 – 2021 елларга Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» Муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 24 ноябрендәге 455 номерлы карары белән расланган «2015 – 2021 елларга Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
10.02.2020 елның 130 номерлы
карарына кушымта

**«2015 – 2021 елларга Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» Муниципаль программасы**

Паспорт

| | |
|---|---|
| Программаның исеме программаны | «2015 – 2021 елларга Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның заказчысы | «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге |
| Программаны Эшләүче | Кукмара муниципаль районы Башлыгы каршындагы Коррупциягә каршы тору комиссиясе |
| Программаның максаты: | Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә каршы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларны һәм механизмнарны камилләштерү.<br>2. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү юлы белән норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү.<br>4. Коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;<br>5. Муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;<br>6. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү. |

<table>
<tr><td></td><td>7. Эшмәкәрлеккә административ басымны эзлекле рәвештә киметү.<br>8. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>9. Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү.<br>10. Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы торуларын стимуллаштыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2015 – 2021 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеп, программаны финанслау күләме</td><td>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 235,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сумнарда)
<table>
<tr><th>Елы</th><th>ТР Кукмара муниципаль районының җирле бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>10,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>23,8</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>36,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>36.8</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>33,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>48,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>48,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>235,6</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча 2021 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән җирле үзидарә органнары өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>- аларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив хокукый актлар өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>- иҗтимагый оешмаларның коррупциягә каршы тору</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | процессларында активлыкларын арттыру;<br>- җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар һәм оешмалар өчен ачык һәм һәркем файдаланырлык булуы, аларның граждан җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту;<br>- район җирле үзидарә органнарының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмнарны кертү тулысынча 100 процентка җитәчәк;<br>-җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт белән бәйле тыюларны һәм чикләүләрне үтәү;<br>- коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр өлеше 90 процентган да ким булмаска тиеш;<br>- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе 90 проценттан да ким булмаска тиеш;<br>- яшәү урыны буенча «бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге булган гражданнар өлеше кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- район рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенең законнарга һәм бердәм таләпләргә туры килүе – 100 процент;<br>- коррупциион хәлгә эләккән халык өлеше социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча 5 проценттан да артмый. |

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, проблемалар һәм аларны чишү юллары

Коррупция дәүләтнең һәм җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә тискәре йогынты ясый, конкурентлыкка сәләтле икътисад формалаштыруда киртә булып тора, халыкның тормыш-көнкүреше үсүгә, гражданлык җәмгыяте үсешенә комачаулый.

Кукмара муниципаль районында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте стратегиясен, Кукмара муниципаль районында 2012 – 2014 елларга коррупциягә каршы муниципаль программаны тормышка ашыру барышында җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы эшчәнлекне координацияләү системасы төзелде.

Районның муниципаль учреждениеләрендә коррупциягә каршы көрәш буенча комиссияләр рәвешендә координация органнары булдырылды; коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затлар билгеләнде;

муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия төзелде, район җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы арасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча бердәм комиссия төзү һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү өлешендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзелде; Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе билгеләнде; югарыда санап үтелгән һәр субъектның коррупциягә каршы торуы буенча төгәл мәсьәләләр билгеләнде.

Алдагы коррупциягә каршы программалар чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә коррупциягә каршы эшчәнлектә граждан җәмгыяте институтларының роле арту билгеләнә. Шулай итеп, җәмәгатьчелек вәкилләре Коррупциягә каршы көрәш комиссиясе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү буенча комиссияләр составына кертелгән, үткәрелә торган төрле чараларда катнашалар. Массакүләм мәгълүмат чаралары коррупциягә каршы эшчәнлекнең актив катнашучылары булды, нәтиҗәдә җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түземсезлек формалаша.

Югарыда телгә алынган коррупциягә каршы тору (профилактика) өлкәсендә проблемаларны хәл итүгә ярдәм итәчәк:
халыкка реаль коррупцион хәл турында һәм районда коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча күрелә торган чаралар турында халыкка мәгълүмат бирү;
коррупциягә каршы тору өчен шартлар тудыру һәм коррупцион хокук бозуларны кисәтү;
җирле үзидарә органнарының граждан җәмгыяте белән хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру, коррупциягә каршы тору буенча иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү;
коррупциягә каршы торуга юнәлтелгән гамәлдәге хокукый, белем бирү һәм тәрбияви чараларны эзлекле куллану.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары

Программаның максаты – коррупция сәбәпләрен ачыклау, аңа этәрә торган сәбәпләргә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тора алмаучылыкны булдыру.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларны һәм механизмнарны камилләштерү.

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне оештыруны камилләштерү;

коррупциягә каршы мониторинг үткәрү;

коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;

муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән

элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;

муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны оештыру һәм уздыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү;

эшмәкәрлеккә административ басымны эзлекле рәвештә киметү;

хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыру;

көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү;

муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы торуларын стимуллаштыру.

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2015 – 2021 еллар. Программаны тормышка ашыру этаплары билгеләнми.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада каралган чараларны финанслау күләме программага кушымтада күрсәтелгән.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2015 – 2021 елларда районның җирле бюджеты акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 235,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Елы | Районның җирле бюджеты акчалары күләме – мең сум |
|---|---|
| 2015 | 10,0 |
| 2016 | 23,8 |
| 2017 | 36,0 |
| 2018 | 36,8 |
| 2019 | 33,0 |
| 2020 | 48,0 |
| 2021 | 48,0 |

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм, район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа белән идарә итү һәм аны тормышка ашыру барышын контрольдә тоту Кукмара муниципаль районы башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Чараларны башкаручылар, тиешле чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплылар район башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе секретаренә чараларның үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

Әлеге программаны гамәлгә ашыруның барышы турында хисаплар елга бер тапкыр район башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе утырышларында тыңлана.

Программа чараларының үтәлеше турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге район сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенең «2015 – 2021 елларга Кукмара муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасы бүлекчәсендә урнаштырыла.

Программаны тормышка ашыруның бөтен чорында нәтиҗәлелегенә бәя программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча аңа кушымтада китерелгән 2021 елга күрсәткечләрне исәпкә алып үткәрелә.

«2015 – 2021 елларга Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына
10.02.2020 елның 130 номерлы
карарына кушымта

# «2015 – 2021 ЕЛЛАРГА КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ СӘЯСӘТНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Максатлары: коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә ярдәм итә торган шартларга каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түземсезлек формалаштыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурыч Коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларны һәм механизмнарны камилләштерү. | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Норматив хокукый актларны эшләү һәм коррупциягә каршы көрәш турында муниципаль районның норматив хокукый актларына федераль һәм республика законнарын үтәү йөзеннән һәм гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нигезендә үзгәрешләр кертү | Кукмара муниципаль районы Советы, Башкарма комитетының юридик бүлеге | 2015 – 2021 еллар | - Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән җирле үзидарә органнары өлеше, процент | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2. РФ Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 01 ноябрендәге ПУ-711 номерлы указларына йөкләнгән функцияләр нигезендә кадрлар хезмәтләренең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү, югарыда күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыручы кадрларның тотрыклылыгы принцибын үтәү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.1. Муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы тору турындагы законнар | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| таләпләрен үтәп, түбәндәгечә тәкъдим ителүче хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү уздыру:<br>муниципаль хезмәткәрләр булып;<br>муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып.<br>Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар турында ТР Прокуратурасы органнарына хәбәр итү | башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары, район прокуратурасы (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны үтәвен тикшерү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары район прокуратурасы (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.3. муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки барлыкка килү мөмкинлеге турында законда билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленә кергән мәгълүматны тикшерү үткәрү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары, район прокуратурасы (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.4. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында мәгълүматларны тикшерү | кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары, район | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| | прокуратурасы (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.5. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан функцияләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупцион куркынычларны системалы рәвештә бәяләүне үткәрү һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү | Район башлыгы ярдәмчесе, кадрлар хезмәтләренең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | ел саен | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.6. Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлар эшчәнлегендә махсус программа белән тәэмин итү базасында эшләнгән компьютер программаларын түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру максатларында гамәлгә кертү һәм куллану:<br>тиешле исемлекләргә кертелгән вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы затлар, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан, керемнәр, күчемсез милек (шул исәптән чит илләрдә), транспорт чаралары, счетлар, кредитлар, кыйммәтле кәгазьләр турында мәгълүматлар базасын кулланып, керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны мониторинг һәм автоматлаштырылган анализ уздыру;<br>граждан-хокукый шартнамә (граждан-хокукый шартнамәләр) шартларында вазыйфаны биләүгә яисә әлеге оешмада хезмәт килешүе шартларында эшне (әлеге оешмада хезмәт күрсәтүне) башкаруга әлеге оешма белән дәүләт, муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) | Мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне үстерү бүлеге, кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | Кертү – 2015 ел<br><br>Куллану – 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| бурычларына керсә, ризалык бирү турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен җыю, системалаштыру һәм карау | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.3. Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү, шул исәптән алар эшчәнлегенә иҗтимагый советлар һәм гражданлык җәмгыяте институтларын җәлеп итү юлы белән дә | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәве буенча һәм федераль һәм республика законнары таләпләре нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиянең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | Район башлыгы урынбасары, Кукмара районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия секретаре | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | |
| 1.5. Закон нигезендә, Кукмара муниципаль районы сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында законнар белән билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә мәгълүмат урнаштыру | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне үстерү бүлеге башлыгы | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1.6. Устав бурычлары коррупциягә каршы торуда катнашу булган иҗтимагый берләшмәләр, иҗтимагый советлар һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтлары катнашында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән, шул исәптән бүләкләр алуга, бүтән түләүле эш башкаруга кагылышлы тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату чаралары комплексын эшләү, бурычы коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2016 – 2021 еллар. | Эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары өлеше – процент | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 10 0 | 100 | | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.7. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән һәр очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2016 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.8. Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәмәү очракларын ачыклау буенча эш алып бару юлы белән муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2016 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.9. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен бозган затлар турында халыкка игълан итү һәм аларга карата ТР | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны | 2016 – 2021 еллар. | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Кукмара районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе утырышында әлеге мәсьәлә буенча фикер алышуга бәйле рәвештә законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллану | профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары, район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.10 Кукмара районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрү | Кукмара районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе әгъзалары | 2016 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.11. «Кукмара РҮХ» ГАУЗда, Башкарма комитетның Мәгариф идарәсендә, Башкарма комитетның Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсендә, Кукмара районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсендә коррупцияне кисәтү буенча эш турында | Баш табиб, Мәгариф идарәсе башлыгы, УДМС начальнигы, Мәдәният идарәсе башлыгы | 2016 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.12. Коррупцион күренешләрне киметү һәм су һәм урман законнарын бозуларны кисәтү өчен, урманнардан һәм су саклау зоналарыннан законсыз файдалану һәм төзү белән бәйле хокук бозуларны ачыклау өчен халыкны җәлеп итү максатларында «Халык инвентаризациясе» акциясе үткәрү. Ачыкланган бозуларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрергә | Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары; Кукмара районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 2016 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 бурыч Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү юлы белән норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү. | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны нәтиҗәле уздыруны оештыру, аны үткәрү | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына | 2015 – 2021 еллар | Проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив | 95 | 96 | 96 | 97 | 97 | 98 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| нәтиҗәләрен ел саен гомумиләштерү буенча гамәли чаралар кабул итү | коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар | | хокукый актларның өлеше – процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен кирәкле шартлар тудыру | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар, район Башлыгы ярдәмчесе, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне үстерү бүлеге башлыгы | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 3 нче бурыч Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1.Кукмара районы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Кукмара районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе | 2015 – 2021 еллар | Социологик сораштырулар оештыру буенча дәүләт йөкләмәсен үтәүнең тулылыгы – процент | 100 | 10 0 | 100 | 100 | 100 | 10 0 | 100 | | - | - | - | - | | - | - |
| 3.2. Максатчан төркемнәр арасында коррупцион факторларны һәм коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча тармак тикшеренүләре үткәрү. Коррупциягә каршы тору кысаларында саклык (превентив) чаралары эшләү өчен алынган нәтиҗәләрне куллану | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.3. Мониторинг үткәрү: коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга граждан җәмгыяте институтларын җәлеп итү; коррупция темасына район массакүләм мәгълүмат чаралары материаллары | Кукмара районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе; Районның иҗтимагый Советы (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 4 нче бурыч Коррупциягә каршы укытуны активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, коррупциягә каршы торуга граждан җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 4.1. Коррупциягә каршы торуда катнашучы аерым категория хезмәткәрләрнең, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән кыска сроклы махсуслаштырылган семинарлар оештыру һәм үткәрү | Район Советы Аппараты җитәкчесе | 2015 – 2021 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | - | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | 50 | | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.2. Әлеге эшкә иҗтимагый советларны, коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләрендә коррупциягә тискәре караш формалаштыру буенча эшне гамәлгә ашыру | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлар | | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль оешмалар өлеше | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3. Кукмара муниципаль районы мәгариф учреждениеләре укучылары, эшләүче яшьләр катнашында коррупциягә каршы түземсез мөнәсәбәт формалаштыру, хокукый аң һәм хокукый культура дәрәҗәсен күтәрү мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән фәнни-дискуссия, шулай ук мәгълүмати-агарту, шул исәптән Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган иҗтимагый акцияләр циклын үткәрүне оештыру | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2015 – 2021 еллар | Үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр, очрашулар, дебатлар, форумнар, «түгәрәк өстәлләр» һәм семинарлар саны | - | - | - | - | - | - | - | | УДМС -10,0 | УДМС-15,0<br>УК-8,8 | УО-10,0<br>УДМС-21,0 | УО-15,0<br>УДМС-5,0<br>УК-16,8 | УДМС - 21,0<br>УК - 12 | УО-10,0<br>УДМС - 21,0<br>УК-12 | УО-10,0<br>УДМС-21,0<br>УК-12 |
| 4.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне, тыюларны үтәве буенча, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү, шул исәптән бүләкләр бирү һәм алуга кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча да оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.5. Коррупциягә каршы тору өлкәсендәге халыкара актларның ришвәт бирү яки ришвәт алу вәгъдәләрен, ришвәт бирү яки | Район башлыгы ярдәмчесе, кадрлар хезмәтләренең | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| ришвәт алу тәкъдимнәрен криминальләштерү турында нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрләрнең үз-үзен тотышы әйләнә-тирәдәгеләр тарафыннан ришвәт бирүне вәгъдә итү яки тәкъдим итү яки ришвәт алырга ризалык яки ришвәт бирүне үтенү буларак кабул ителергә мөмкин булган хәлне булдырмау буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.6. Җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гражданнарны коррупциягә каршы агартуга юнәлдерелгән чараларда катнашуын тәэмин итү (тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләренә багышланган радиопрограммаларда катнашу, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган статьяларда коррупциягә каршы законнарны аңлату юлы белән) | Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5 нче бурыч. дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.2. Административ регламентлардан файдаланганда, шул исәптән ахыргы хезмәтләрне кулланучыларны сораштыру юлы белән дә, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты мониторингын үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2015 – 2021 еллар | Гражданнарның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе, процентларда | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 5.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын камилләштерү, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында да | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2015 – 2021 еллар | - яшәү урыны буенча «бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, процент<br>Бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләренең бер дәүләт хезмәте алу өчен җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләренең уртача саны | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | - | - | - |
| | | | | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.4. «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларының бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата Бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлыТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә Кукмара муниципаль районы рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген тулыландыруны оештыру | Район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия секретаре, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затлар | 2015 – 2021 еллар | «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларының бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата Бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлыТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә үзенең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итүче муниципаль районның җирле үзидарә органнары өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | - | - | - |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 5.5. Гражданнарга үзләренә билгеле булган коррупция фактлары, аларны кылуга этәрә торган сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирүче «ышаныч телефоннар», «кайнар линияләр», интернет-кабул итү бүлмәләре, башка мәгълүмати каналлар эшчәнлеген тәэмин итү | Коррупциягә каршы тору буенча Комиссия | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 5.6. Коррупциягә каршы көрәш һәм районда коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында еллык отчетларны әзерләү һәм районның рәсми сайтында урнаштыру | район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 5.7. Коррупциягә каршы комиссияләр утырышларында квартал саен гомумиләштереп һәм аның нәтиҗәләрен карап тикшереп, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрдә булган вазифаи затлар эшчәнлегендә коррупцион күренешләр турында мәгълүмат мониторингын үткәрү эшен оештыру | Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 5.8. Коррупциягә каршы эчтәлекле мәгълүматны тапшыруның махсус мәгълүмат стендларын һәм башка формаларын оформить итү һәм актуаль хәлдә тоту | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | 5,0 | - | - | 5,0 | 5,0 |
| 5.9. Коррупциягә каршы тору буенча район җирле үзидарә органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларына җиткерү | Кукмара районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 5.10. «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы битләрендә «Кукмара авазы» радиосы буенча мәгълүмат кабатланып, Кукмара муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча район | «Хезмәт даны» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| комиссиясе эшчәнлеген яктырту, «Кукмара авазы» радиосында һәм kukmor-rt.ru сайтында мәгълүматны кабатлау | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.11. Программаны тормышка ашыру кысаларында районда планлаштырылган чараларны яктырту | «Хезмәт даны» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.12. Коррупциягә каршы юнәлешле газета полосасын чыгару, әлеге тема буенча халыктан елга 1 тапкыр сораштыру | «Хезмәт даны» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.13. Газетада коррупциягә каршы юнәлештәге хокук саклау органнарының мәкаләләрен бастырып чыгару, аларның бу юнәлештә эшчәнлеген яктырту. | «Хезмәт даны» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.14. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эш башкаручы район оешмалары эшчәнлеген контрольдә тотуны оештыру | Кукмара районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч 6. Муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру, эшмәкәрлеккә административ басымны эзлекле рәвештә киметү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.1. Юридик затлар исеменнән яисә мәнфәгатьләрендә коррупциячел күренешләрне кисәтү һәм булдырмау буенча чаралар үткәрү | Кукмара районы Башкарма комитеты каршындагы Эшмәкәрләр советы (килешү буенча), Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.2. Субсидияләр алуның нигезлелеген, бюджет акчаларыннан максатчан файдалануның дөреслеген тикшерүне оештыру | Кукмара районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.3. Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен куллануны һәм әлеге мөлкәттән файдалануга хокукларны тапшыру һәм аны читләштерү тәртибен контрольдә тотуны оештыру | Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, Контроль-хисап палатасы, прокуратура (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Бурыч 7. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү. | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алуларны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган сатып алуларның ачыклыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү буенча чаралар уздыру, шулай ук сатып алуларда катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч 8. Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.1. Гражданнар муниципаль хезмәт вазыйфасына кергәндә барлыкка килә торган коррупцион куркынычларны бетерү максатларында муниципаль хезмәт өлкәсендә закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2015 – 2021 еллар | Үз проблемаларын хәл итү өчен вакыт яки мөмкинлекләре булмау сәбәпле, коррупцион алыш-бирешкә кергән район халкының өлеше – процентларда (социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) | - | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - | | - | - |
| 8.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның электрон чират нигезендә балалар бакчаларына керү чиратын саклауны тәэмин итү. Чиратны нигезсез күчерү мөмкинлеген булдырмау.<br>ТР мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында комплектлау процессы мониторингын ай саен үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 8.3. Кукмара муниципаль районы белем бирү учреждениеләре тарафыннан бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү һәм алардан файдаланганда законнарның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Кукмара районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Программаның исеме төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | Значениеләре индикаторлары | | | | | | | Финанслау (Татарстан Республикасы Кукмара районы бюджеты хисабына), мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 8.4. Мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә коррупция күренешләре турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен мониторинглауны алып бару | ТР Кукмара районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, «Кукмара РҮХ» ГАУЗ (килешү буенча), | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 8.5. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Кукмара районы буенча бүлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар күрүне тәэмин итү, шул исәптән бу эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү юлы белән дә | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2015 – 2021 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | | - | - |
| 8.6. Кукмара районы авыл җирлекләре территориясендә законсыз миграция фактларын ачыклау эшен оештыру | Кукмара районы башкарма комитеты; Кукмара районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Программа буенча Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына барлыгы | | | | | | | 235,6 мең сум | | | | | | | | | | | |